КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 15 ноябрь г.Казань № 880

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар үткәрү белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 28 май, 381 нче карары белән расланган Физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар үткәрү белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар үткәрү белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 28 май, 381 нче карары белән расланган Физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы

өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар үткәрү белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\880.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 28 май, 381 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 15 ноябрь, 880 нче
карары редакциясендә)

Физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар үткәрү белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр, чаралар) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр чараларны үткәрүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) максатларында бирелә.

3. Субсидияләр алучылар – эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы юридик затлар (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән башка) (алга таба – субсидияләр алучылар).

4. Субсидияләр Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан бирелә; аңа тиешле финанс елына субсидияләр бирү өчен Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә бюджет акчасы алучы буларак бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән була.

5. Финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидияләр (каплау өчен субсидияләр бирелә торган чыгымнар) булган чыгымнарның юнәлешләре түбәндәгеләр:

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләү;

ирекләләр чыгымнарын каплау;

корылмалар (вакытлыча төзелгән корылмаларны, урыннарны, мәйданчыкларны, транспортны да кертеп) хезмәтләренә (аренда, техник хезмәт күрсәтү) түләү;

чараларны тормышка ашыру өчен кирәкле техник чараларны һәм ярдәмче җайланмаларны арендалау, сатып алу;

чараларны тормышка ашыру өчен полиграфия продукциясе һәм канцелярия товарлары әзерләү һәм сатып алу;

чараларда катнашучыларның, бөтенроссия һәм халыкара иҗтимагый оешмалар вәкилләренең, чара регламенты буенча мәҗбүри булырга тиешле техник белгечләрнең яшәү, туклану, тәүлек һәм юл йөрү чыгымнары;

Татарстан Республикасының спорт төрләре буенча җыелма командалары әгъзалары – спортчылары өчен кирәкле спорт инвентаре һәм экипировкалары сатып алу;

җәлеп ителгән белгечләрнең, хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәте өчен түләү;

чараларны тормышка ашыру өчен кирәкле урыннарны, мәйданчыкларны, корылмаларны (вакытлыча төзелгән, төрле рәвештәге конструкцияләрне дә кертеп) бизәү (аларны монтажлауны һәм демонтажлауны да кертеп);

чараның реклама кампаниясен үткәрү, мәгълүмат бирә торган басма продукция әзерләү һәм тарату (аны монтажлауны һәм демонтажлауны да кертеп), фотосурәткә һәм видеога төшерүне гамәлгә ашыру, видеороликлар һәм видеофильмнар ясау, аларны ротацияләү;

сувенир продукцияләр һәм бүләкләр әзерләү һәм сатып алу;

чараларны ачу һәм ябу тантаналарын, аларның мәдәният программасын һәм экскурсия хезмәте күрсәтүне оештыру;

программа һәм мәгълүмат белән тәэмин итү, IT-технологияләр;

чараларда медицина хезмәткәрләре озатып йөрүне һәм биологик медицина белән тәэмин итүне гамәлгә ашыру, ашыгыч ярдәм автомобиле белән күрсәтелгән хезмәтләргә түләү;

чараларда катнашучыларны чара вакытында килеп чыккан бәхетсезлек очракларыннан (дәвалауның барлык этапларындагы чыгымнарны каплауны һәм иминият түләүләре исәбеннән тернәкләндерүне исәпкә алып) иминләштерү;

чара куркынычсызлыгын тәэмин итү;

элемтә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре хезмәтләре, почта чыгымнары;

чараларда катнашучыларны аккредитацияләү;

чараларны үткәрү өчен кирәкле техник чаралар өчен ягулык-майлау материаллары;

чараларда катнашучылар өчен эчәргә яраклы су;

спорт корылмаларын, яссы корылмаларны, басуларны сертификацияләү;

чаралар үткәрүгә турыдан-туры бәйле булган оештыру кертемнәре.

6. Субсидияләр субсидия бирү турындагы килешүне төзү планлаштырыла торган айдан соң килүче айның бересенә түбәндәге таләпләргә туры килүче юридик затларга бирелә:

чаралар оештыруны һәм үткәрүне гамәлгә ашыра;

законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра;

субсидияләр алучыларның Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият

кертемнәре, пеняләр, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булмаска тиеш;

субсидияләр алучыларның субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка норматив актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнелмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында вакытында түләнелмәгән башка бурычлары булмаска тиеш;

субсидияләр алучылар – юридик затлар үзгәртеп оештыру, ябу, банкротлык процессында тормаска тиеш;

чит ил юридик затлары, шулай ук Россия юридик затлары (аларның устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы белән раслана торган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм финанс операцияләрен үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аның теркәлү урыны булган чит ил юридик затларның катнашу өлеше барысы бергә 50 проценттан артыграк булган) субсидияләр алучылардан булмаска тиеш;

субсидияләр алучылар бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан башка норматив хокук актлары нигезендә акча алмаска тиеш.

7. Субсидия алу өчен юридик зат Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык тарафыннан раслана торган форма буенча исәп-хисаплар һәм чыгымнарны нигезләүләр теркәлгән субсидия бирүгә гариза (алга таба – гариза);

юридик затның гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга кертелгән барлык үзгәрешләрне кертү турындагы документлар күчермәләре;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка норматив актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнелмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында вакытында түләнелмәгән башка бурычлары булмавын раслый торган документлар;

юридик затның үзгәртеп оештыру, ябу, банкротлык процессында тормавын раслый торган документлар;

юридик затның башка норматив хокук актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга акча алучы булмавын раслый торган документлар;

чыгымнар күләмен нигезли торган мәгълүматны һәм аны алу чыганагын (чаралар үткәрүгә сарыф ителгән фактагы чыгымнарны (исәпләр, исәп фактуралары, товар-транспорт йөкнамәләре, түләү йөкләмәләре, башкарылган эшләрне кабул итү актлары) раслый торган документлар) күрсәтеп, чыгымнар юнәлешләре бәясе исәпләнгән булырга тиешле финанс-икътисадый нигезләмә теркәлгән, юридик зат җитәкчесе тарафыннан расланган һәм Министрлык белән килештерелгән чаралар үткәрүгә чыгымнар сметасы.

7. Юридик зат үз теләге белән түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

юридик зат буларак юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык күчермәсе яки Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына язу бите күчермәсе;

юридик затны салым органына исәпкә кую турындагы таныклык күчермәсе;

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеняләр, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булмавын раслый торган документлар;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка норматив актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнелмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында вакытында түләнелмәгән башка бурычлары булмавын раслый торган документлар.

Юридик зат тарафыннан бу пунктның тугызынчы – уникенче абзацларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

8. Гаризалар кабул итү башлану һәм тәмамлану вакытлары, гаризаларны карап тикшерү графигы Министрлык боерыгы белән раслана. Әлеге мәгълүмат гаризалар кабул итү башлану көненә кадәр эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

9. Министрлык документлар теркәлгән гаризаларны кабул итә һәм аларны кергән көненнән бер көн эчендә теркәүгә ала.

10. Министрлык гаризаны теркәүгә алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 20 көн эчендә карый һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында боерык рәвешендәге карар кабул итә.

11. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

бу Тәртипнең 7 нче пунктындагы икенче – җиденче абзацлары белән күздә тотылган документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

юридик зат бу Тәртипнең 6 нчы пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү;

юридик зат тарафыннан тапшырылган гаризадагы һәм бу Тәртипнең 7 нче пунктында күрсәтелгән документлардагы мәгълүмат дөрес булмау.

12. Кабул ителгән карар нәтиҗәләре турындагы белдерү кәгазе юридик затка Министрлык тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көннән бер көн эчендә язма рәвештә җибәрелә.

13. Субсидияләр бирү Министрлык һәм субсидияләр бирү турындагы карар кабул ителгән субсидияләр алучылар белән субсидияләр бирү турында төзелгән килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирү турындагы килешү субсидия бирү турындагы карарны билгеләнгән тәртиптә кабул иткән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән расланган бертип форма нигезендә төзелә.

Субсидия бирү турындагы килешүдә субсидиянең күләме, аның максатчан билгеләнеше, чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнар төре, субсидияне күчерү тәртибе, субсидияне файдалану турында хисап бирү тәртибе һәм вакытлары, субсидияне (субсидиянең калган өлешен) кире кайтару очрагы һәм тәртибе, Министрлык тарафыннан, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән килештерелеп, субсидиянең файдаланылмый калган өлешен файдалануга ихтыяҗ турындагы карар кабул ителгәндә, хисап финанс елында финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шарт, Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм аны бирү тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрү өчен субсидия алучының (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый оешмалар катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында коммерция оешмаларыннан башка) ризалыгы, субсидия алучының бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәве турындагы нигезләмәләр, югары технологияле импорт җайланмаларын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта турындагы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән башка, субсидия акчасы исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю карала.

14. Чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидия күләме законнар нигезендә төзелгән һәм Министрлык белән килештерелгән чара оештыруга һәм үткәрүгә чыгымнар сметасы нигезендә билгеләнә.

15. Чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$С = З_1 + З_2 + З_3 ... + З_n,$$

монда:

С – субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме;

$З_1, З_2, З_3 ... З_n$ – бу Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнар.

16. Министрлык субсидия бирү турындагы карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә субсидияне субсидияләр алучыларның кредит оешмаларында ачылган хисап исәпләренә күчерә.

17. Субсидияләр алучылар субсидия керү һәм аны тоту буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.

18. Субсидияләр алучылар Министрлыкка субсидия бирү турындагы килешү белән билгеләнә торган вакытларда һәм формаларда субсидияне файдалану һәм субсидияне файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисап кертә.

19. Субсидияне файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү, субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән субсидияне файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешүдән чыгып, Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

20. Субсидияләр алучылар тарафыннан субсидияләр Татарстан Республикасы бюджетына Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшырылган;

субсидияне файдалану турындагы хисап билгеләнгән вакытта тапшырылмаган;

субсидия биргәндә билгеләнгән, Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартлар бозылган;

субсидия акчасы максатчан файдаланылмаган.

Субсидия алучы тарафыннан субсидияне кире кайтару вакытлары бозылган очракта, Министрлык субсидияне кире кайтару вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

Әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

21. Хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше булган очракта, алучының аны файдалануга ихтыяҗы булу турындагы карар, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән килештерелеп, Министрлык тарафыннан кабул ителә.

Әлеге карар булмаган очракта, алучы субсидиянең калган өлешен хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә кире кайтарырга тиеш.

22. Субсидияләр алучылар тарафыннан бу Тәртипнең 20 нче һәм 21 нче пунктларында күрсәтелгән субсидияләрне кире кайтару вакытлары бозылган очракта, Министрлык субсидияләрне кире кайтару вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

23. Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне законнар белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

24. Субсидияләрне максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыра.